РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 26 2026 елның 15 апреле

**«Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет-финанс сәясәте нигезләмәләрен раслау турында» 2005 елның 29 декабрендәге 25 номерлы Түбән Кама муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет-финанс сәясәте нигезләмәләрен раслау турында» 2005 елның 29 декабрендәге 25 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

14 статьяның 2 пунктының җиденче абзацында «Россия Федерациясе бюджет системасы,» сүзләреннән соң «шул исәптән дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне арендалау һәм гамәлгә ашыру өчен түләүләрне,» сүзләрен өстәргә;

35 статьяның 4 пунктының өченче абзацында «һәм гамәлгә ашырганда» сүзләрен «дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны үзәкләштерү нәтиҗәсендә һәм гамәлгә ашырганда бюджет акчаларын экономияләү барлыкка килү» сүзләренә алмаштырырга;

35 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- бюджет ассигнованиеләре ашыгыч гуманитар җавап бирү, гуманитар ярдәм күрсәтү йөкләрен китерү, халыкны эвакуацияләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанс белән тәэмин итүгә яңадан кертелгән очракта»;

46 статья исемендә «Төзү» сүзеннән соң «, тәкъдим итү һәм раслау» сүзләрен өстәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләгән тәртиптә рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Советының социаль-икътисадый үсеше, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы Р.И. Беляев